РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
КОШКИ-ТЕНЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУШКЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 апрель 2025 года №1-97

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлеге Советының 2013 елның 18 февралендәге 1-34 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Күшке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын гамәлдән чыгару хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Шәһәр төзелеше эшчәнлегендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Күшке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 05 мартындагы 210/о номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлеге Советының 2013 елның 18 февралендәге 1-34 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Күшке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http:pravo.tatarstan.ru адресы буенча басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында https://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча халыкка игълан ителергә тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Күшке авыл җирлеге башлыгы А.В. Стрелков